РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Монашевского
сельского поселения Менделеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Советы

---

# Р Е Ш Е Н И Е

# К А Р А Р

От 29.12.2025 года

№ 13

Монашево авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2023 елның 16 июнендәге 91 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, рәисләр, рәис урынбасарлары, контроль-хисап органнары аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында “2018 елның 28 мартындагы 182 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2025 елның 25 ноябрендәге 994 нче номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советы
КАРАР КЫЛДЫ:

1. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлы күләмен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладлы күләменә тапкырлы «15389» күләмен «16928» санына алмаштырырга.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2023 елның 16 июнендәге 91 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1 Карарның 1 нче кушымтасында «21091» санын «23201» санына алыштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Монашево авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Монашево авыл җирлеге Советы рәисе Р.Ф. Иосифов